КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 декабрь г.Казань № 1601

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 425 нче карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 425 нче карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча

вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «дәүләт корпорациясеннән – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм күрсәтү фондыннан» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин